ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-74-16, факс:2-62-20, e-mail:jutaza@tatar.ru, adm_jutaza@mail.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**14 ноябрь 2019 ел.** **№ 842**

2020 елга “Ютазы муниципаль
районы» муниципаль берәмлегенең балаларга
өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү,
экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик,
социаль-икътисадый, табигать фәннәре, техник
һәм культурология юнәлешләрендәге мәгариф
оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем
бирүче күп профильле мәгариф оешмаларының
чыгымнар нормативын раслау турында

«Мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрен туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигать фәннәре һәм фәнни-техник өлкәләрдәге нормативларны исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы карары һәм “Ютазы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар кабул итә:

1. 2020 елга расларга:

«Ютазы муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигать фәннәре, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүче күп профильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга кушымта итеп бирелгән чыгымнар нормативын;

балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге өстәмә белем бирү оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү күппрофильле мәгариф оешмаларында

0,5 күләмендә өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга чыгымнар нормативына карата төзәтү коэффициентын.

2. Ютазы муниципаль районының финанс-бюджет палатасына тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү буенча мәгариф оешмаларын финанслауны;

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары чоры дәвамында хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан карауны.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе А. Ә. Шафигуллин

А.В. Сучкова
2-80-12

Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расландылар
«___» __________20__ ел № ____

**“Ютазы муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында туристик-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигать фәннәре, техник һәм культурология юнәлешендәге өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыру өчен ЧЫГЫМНАР НОРМАТИВЫ**

| Өстәмә белем бирү программалары юнәлеше | Урнашкан территориясе | Чыгымнар нормативы, 1 укучыга елга сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Беренче уку елы | Икенче уку елы | Өченче һәм киләсе уку еллары |
| Сәнгать-эстетик | шәһәр җире | 5 569 | 10 314 | 12 376 |
| | авыл җире | 5 970 | 11 055 | 13 266 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җире | 5 468 | 10 126 | 12 151 |
| | авыл җире | 5 868 | 10 867 | 13 041 |
| Техник иҗат | шәһәр җире | 5 873 | 10 876 | 13 051 |
| | авыл җире | 6 273 | 11 617 | 13 940 |
| Туристик-туган якны өйрәнү | шәһәр җире | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Экологик-биологик | шәһәр җире | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Хәрби-патриотик | шәһәр җире | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Социаль-педагогик | шәһәр җире | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | авыл җире | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Социаль-икътисади | шәһәр җире | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | авыл җире | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Табигать фәннәре | шәһәр җире | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җире | 6 071 | 11 242 | 13 491 |